**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 13.10.2020** **№ 782**

# Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 09 февралендәге 368 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне оештыру һәм уздыруның һәм муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау Тәртибенең 1.11. пунктына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2014 елның 07 мартындагы 14-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» ТР Законы нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты, **КАРАР БИРӘ**:

1. Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 09 февралендәге 368 нче номерлы карары (27.07.2020 № 580 Карары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне оештыру һәм уздыруның һәм муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау Тәртибенең 1.11. пунктында «һәм инвестиция эшчәнлегенең,» сүзләреннән соң «мөмкин» сүзен төшереп калдырырга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты эшләре белән идарә итүчесе Г.Ф. Сабировага йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин